Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты

Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАРЫ

19 апрель, 2024 ел № 71

«Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе төзү турында» 2024 елның 21 мартындагы 62 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы, «Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 20 мартындагы 177 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы кадастр эшләрен оештыру турында» 2020 елның 31 мартындагы 237 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе төзү турында» 2024 елның 21 мартындагы 62 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтада комиссиянең әгъзасы А.А. Вәлиевне (Идел буе СРО) И.В. Мурингә алмаштырырга.

2. Карарның калган пунктларын үзгәрешсез калдырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.И. Шәйхисламов